ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24 гыйнвар 2025ел № 403

Башкарма комитетның 2022 елның 4 августындагы 3945 номерлы Карары белән расланган элек приватизацияләнгән торак урыннарны муниципаль милеккә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 4 августындагы 3945 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2023 елның 2 июнендәге 4678 номерлы Карары редакциясендә) расланган элек приватизацияләнгән торак урыннарны муниципаль милеккә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, 1 нче кушымтаны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 24 гыйнварындагы
403 номерлы карарына
кушымта

«Элек приватизацияләнгән торак урыннарны муниципаль милеккә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Башкарма комитет Җитәкчесенә

кемнән ___________________________________
_______________ (алга таба – гариза бирүче)
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) , паспорт мәгълүматлары, яшәү урынын теркәү турында мәгълүматлар, телефон)

Элек приватизацияләнгән торак урыннарны муниципаль милеккә алу турында
гариза

Элек приватизацияләнгән, мәйданы ____ кв.м, кадастр номеры ___________ булган торак урынны муниципаль милеккә алуны сорыйм.

Торак урынның адресы:
______________________________________________________________________________

Гаризага түбәндәге сканерланган документлар теркәлә:

1) шәхесне раслаучы документ;

2) гариза бирүче вәкиленең шәхесен һәм вәкаләтләрен раслаучы документлар (әгәр гариза бирүче исеменнән гариза бирүченең вәкиле эш итсә);

3) торак урынга милек хокукын раслый торган документ (әгәр милек Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән булса);

4) яшәү урыны буенча теркәлү турында белешмә;

5) торак урынның техник паспортының күчермәсе;

6) Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлегенең торак урынны муниципаль милеккә түләүсез тапшыру турында рөхсәте (приватизацияләүдә балигъ булмаган балалар катнашса) (үз инициативасы буенча);

7) йорт кенәгәсеннән өземтә (документ коммерция оешмасы тарафыннан бирелгән очракта) (үз инициативасы буенча).

________ ___________________ ( _________________)
(дата) (имза) (Ф.И.А.и.)

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен түбәндәге ысул белән бирүне сорыйм:

☐ Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетына;

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетына;

☐ Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәгендә;

☐ Башкарма комитетта.

_________ ___________________ ( ___________________)
(дата) (имза) (Ф.И.А.и.)

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева